**ХАЛЫК ЖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 5** **10.11.2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге составына керүче
Урсай  авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 10  ноябрендә Урсай авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез ,1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне 200 сум күләмендә  билгеләп, үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы су башнясын койма белән эйлэндереп алу, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны  кардан чистарту, триммер очен ягулык, трактор очен запас частьлэр  алу);

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (коеларны ремонтлау, бикләрне һәм капкачларны, люкларны алыштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы  катнашучылар исемлегендә 461 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны – 325  кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 325  кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче Урсай авылыдна узган халык җыенын узган,  халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: Сез ,1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне 200 сум күләмендә   алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы су башнясын койма белән эйлэндереп алу, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү,);

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (коеларны ремонтлау, бикләрне һәм капкачларны, люкларны алыштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылының юлларын кардан чистарту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәис _______________ З.Х. Рахимьянова